*Мотигуллина А. Р. (КФУ, Казань),*
*Замалиева Л. Ф. (КФУ, Казань)*

# Г. ИСХАКЫЙ ИҖАТЫНДА ҖӘМГЫЯТЬНЕ ҮЗГӘРТҮ МОДЕЛЕ

**Аннотация:** В статье рассматривается как Г. Исхаки в пределах маленькой литературной сказки-были «Лукман хаким» изобразил модель изменения и переустройства целого государства. Также исследуются взаимоотношения царя и вазира, высшего сословия и народа, мудреца Лукмана хакима и всех остальных жителей поселения.

**Ключевые слова:** татарская литература, жанр, литературная сказка, образная система, герой.

## The model of reforming the society in the books by G. Iskhaki

**Abstract:** The article describes how G. Iskhaki within a small literary tale-were «Lukman hakim» portrayed a model of change and reorganization of the whole state. Also, the relationship between the king and the wazir, the upper estate and people, the sage Lukman khakim and all other inhabitants of the settlement are under consideration.

**Key words:** tatar literature, a genre, a literary tale, imagery, character.

XX гасыр башы татар әдәбиятының күренекле әдибе Г.Исхакый иҗатында һәм иҗтимагый эшчәнлегендә җәмгыять тормышын чагылдырган, халыкның үткәне һәм бүгенгесе,

киләчәге турындагы хыялларын төрле чаралар ярдәмендә башкаларга җиткерергә омтылган. Аның «Алдым-бирдем», «Зөләйха» әсәрләрендә җәмгыятьтә хатын-кызның урыны, роле, «Ике йөз елдан соң инкыйраз», «Тормышмы бу?» әсәрләрендә татар җәмгыятенә, яшәешенә бәя бирелә. «Ул әле өйләнмәгән иде», «Остазбикә» әсәрләрендә гаилә төзелеше, моделе күрсәтелә. Әсәрләр арасында аерым урынны тоткан «Локман хәким» әкиятенә Г.Исхакыйның милли идеясе, халыкның яшәешен үзгәртү юллары, киләчәге турындагы карашлары салынган.

Язылу вакыты ягыннан «Локман хәким» әдәби әкияте 1923-24 нче елларда дөнья күргән әсәр. Безнең көннәрдә «Идел» журналында галим И.Нуруллинның кечкенә генә сүз башы белән басылып чыга [1]. Биредә тәнкыйтьче әлеге әсәрнең жанр табигатен билгеләргә омтылыш ясый. «Жанры ягыннан бу хыялый хикәя. 20 нче елларда Европада һәм бездә активлашып китеп «антиутопия» дип йөртелә торган әсәр җөмләсенә керсә кирәк», – ди. Соңыннан әсәрне җентекләп өйрәнәсе барлыгы турындагы фикерне әйтеп уза. Бу юнәлештә И.Нуруллин башлангычын дәвам итүче, озак еллар дәвамында Г.Исхакый мирасын барлаучы, аны бастырып чыгару эшендә зур көч куючы Л.Гайнанова була. Ул үзенең «Локман хәким һәм Г.Исхакый» мәкаләсендә беренче планга укучыны әсәр белән якыннан таныштыру максатын куйса, икенчедән, анда сурәтләнгән вакыйгаларның безнең көннәр чынбарлыгы белән охшашлыгын дәлилләргә омтыла, һәм ул «Г.Исхакыйның бөек акылы аңа безнең илдәге хәлләрне объектив бәяләргә һәм гасыр башында ук бөтен егерменче гасыр буена булачак афәтләрне алдан күрергә мөмкинлек биргән», – дигән нәтиҗәгә килә [2, с. 34]. Чыннан да, әкият сюжеты белән танышканнан соң, әлеге фикерне инкяр итеп тә булмый, әлбәттә. Ләкин бүгенге көн күзлегеннән генә карап объектив нәтиҗәләр ясап булганлыгы шикле. Шуңа күрә әсәрнең анализ эшен төп герой исеменә тукталудан башлыйк.

Әдәбият тарихына килеп кергәнче үк Локман исемен мөселманнарның изге китабы «Коръән»дә очратабыз. Анда ул «...шәрык халыкларының мифологиясе, фольклоры, язма чыганаклары белән бәйле исем»нәрнең берсе буларак китереп кертелгән [3, с. 29].

Әкияттә Г.Исхакый эстетикасындагы табигать һәм кеше гармониясенең тыгыз бәйләнешенә игътибар ителә. Шуңа күрә әсәрдә табигать һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтләрне бирү даими чиратлаштырып барыла. Әйтик, табигатьтә булып узган хәлләр

кешеләрне үзгәртеп җибәрә: «Яңгыр артыннан көн туган. Халык урамга чыккан. Барысы да матур итеп киенгән, бизәнгән-ясанган, һәркемнең йөзе ачык, гүяки җир йөзендә инде кайгы-хәсрәт тә, дошманлык та, бай белән ярлы, чибәр белән ямьсез, кыю белән куркак арасындагы аермалар да мәңгегә беткән диярсең. Халык шау-гөр килеп бәйрәм иткән, җырлаган-биегән, күңел ачкан».

Г.Исхакый иҗатында җәмгыять төзелешен күз алдына китерү ил белән идарә итүчеләрне сурәтләүдән башлана. Автор патша, вәзир, халык, хәким арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне тасвирлый. Үзәктә торган хәкимнең, сүзе өстен булса да, барлык вакыйгаларны читтән карап торуы гына искәртелә: «...хәким бер сүз дә әйтмәгән – күргәннәрен кәгазьгә теркәп куйган»; «Карт хәким моны да кәгазьгә теркәгән», «Карт хәким моны да кәгазьгә теркәп куйган»; «Карт хәким боларны да теркәп куя»; «Карт хәким бу ахмаклыкларны да теркәп куйган»; «Ә карт хәким бөтен күргән – белгәннәрен кәгазьгә терки барган». Шул рәвешле, кабатлау алымына нигезләнеп, Г.Исхакый акыл иясенең кылган гамәлләренә, халык белән бердәмлектә яшәвенә, аларга якынрак торуына карап, Локман хәкимне гомумиләштерелгән зат итеп күрсәтә.

Ил белән идарә итү мәсьәләләрендә вәзир образының эволюциясен күзәтү дә кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Бу вакыйгаларны күреп вәзир югалып кала: «Менә бер заман халык пышылдаша башлаган: имеш, вәзир акылдан язган, вәзир акылга җиңеләйгән, вәзир акылын җуйган икән», – дигән хәбәр тарала. Вәзиргә халык эчә торган суны эчәргә туры килә. «Шул чакны аның күзләре кызарган, йөзендәге җыерчыклары язылган, гүя ул күңеленә хуш килердәй бер нәрсә күреп, шуның тәэсирендә бөтен мәшәкатьләрен, өстенә йөкләнгән барлык вазифаларын оныткан, күз ачып йомганчы һәммәсен иңеннән кагып төшергән». Вәзирнең терелүе халыкка кабат бәйрәм рухын кайтарган. Әмма патша гына борчуга төшә.

Барлык дөнья асты өскә килгән бер вакытта вәзир һаман үз вазифаларын башкаруын дәвам иткән. Вәзир «үзен барлык вәзирләргә баш итеп саный башлаган. Ул исең-акылың китәрлек әллә нинди ахмаклыклар уйлап таба... Ә көннәрдән бер көнне патша янына шундый тәкъдим белән кергән: янәсе, башкала уртасынан агып, дулкыннары ярга төрле асылташлар вә төрле мәрҗәннәр кагып чыгаручы елганы, шәһәр читендәрәк урнашкан текә тауга таба борсаң,

шул тарафка агарга мәҗбүр итсәң әйбәт иде».

Әмма вәзир, акылдан язуына да карамастан, патшаның барысын да җитди кабул итмәвен аңлап торган һәм аның акылга җиңеләюе турында хәбәр тараткан. Хәким белән киңәшләшкәннән соң, патша да бу суны эчеп җибәргән. «Патшаның акылы җиңеләю дә нәкъ патшаларныкыча булган: ул үзен патшаларның патшасы, акыл ияләренең иң акыллысы дип исәпли икән. Халыкка җиткерелгән беренче фәрманында ук бөтен сүзләрне кире мәгънәсендә аңларга боерган, ә моңарчы гамәлдә йөргән законннарны киресенчә үтәргә кушкан».

Әдәби әкият нигезенә салынган вакыйгалар үзәгендә халык тора. Биредә бер дәүләт эчендәге халыкның яшәеше, тормыш-көнкүреше генә түгел, төрле үзгәрешләргә карата мөнәсәбәте ягыннан да ачыла. Г.Исхакый гомумиләштерелгән образ тудыра. Аларның мул, бай тормышта, бернинди михнәт күрми генә яшәвен сурәтләгәннән соң, яңгыр яву тәэсирендә бергәләп үзгәреш кичерүен дә күрсәтә. Әмма халык бик рәхәт яши, аның яшәешен күрсәтүдә идеаллаштыру ягы да өстен чыга. Әсәр ахырындагы соңгы штрихлар аша гына халык тормышында борылыш булырга тиешлеге аңлашыла.

Әсәрдәге ачык, аксыл төсләр юкка чыга, халык ач, ялангач «халык өстендә сәләмә кием-салым, барысы да ябык, үзләрен бет баскан, мәчет манаралары ауган, мәдрәсә түбәсе җимерелгән, мунчаның фонтаны эшләүдән туктаган... барысы да нидер эзли, як-ягына карана, гүя ки бик кадерле нәрсәләре югалган диярсең», тирә-юньдә харәбәләр, җимереклек, «шәһәр таланган, кая карама ачлык-ялангачлык, юллар эштән чыккан, күперләр ишелгән, арыклар кипкән, бакчалар басуга, басулар болынга әверелгән». Шул рәвешле, Г.Исхакый эпик киңлеккә ия әсәр язып, кыска гына әкият эченә бөтен бер дәүләт язмышын сыйдыруга ирешкән. Әдип сурәтләгән дәүләт дүрт фиркагә бүленгән: «аңгыралар, ахмаклар, акылдан язганнар һәм дә камил акыллылар партиясе барлыкка килгән». Әлеге партияләр эчендә власть өчен көрәш тә барган. Илдә бернинди тәртип тә калмаган. «Ил халкы шулай фиркаләргә бүленеп беткәч, камил акыллылар үзләрен аңгыра дип күрсәтергә тырышкан, аңгыралар ахмак булып кыланган, ахмаклар акылдан язганнар урынына омтылган һәм шул сәбәпле бар халык хәйләгә керешкән: тилебәрән орлыгы ашаган, бәкләр, аксөякләр

эфьюн белән гашиш куллаган, сәүдәгәр халкы әчәргә сабышкан». Илдә тәртип урнаштыру максаты белән җитмеш җиде мең акыллының башы киселгән, бераздан җитмеш җиде мең аңгыра утта яндырылган, чит мәмләкәттән җитмеш җиде мең акылсызны кайтарып караганнар.

Шулай да халык арасында үзара ышаныч беткән, дошманлык арткан. Соңгы исәптә «ил тәмам кыргаксыган, бөлгенлеккә төшкән. Халык арасында кабат ызгыш, суеш башланган». Әдип әкият алымнарынан оста файдаланып, партияләр көрәшен дә, барлык эшләрне дә киресенчә үтәү турындагы фикерләре аша дәүләт белән идарә итүдә гаделлек хөкем сөрергә тиешлеген ассызыклый.

Г.Исхакый ачып биргән Локман Хәким халык фаҗигасен нечкәләп тоючы, аның киләчәген кайгыртучы. Үзе дә җиргә иңдерелгән мәшһәр корбаны. Г.Исхакый ил тарихының төрле якларын үз күзләре белән күргән, аны төрле сәнгать чаралары ярдәмендә тасвирларга омтылган. Ул ил белән идарә итүнең бер моделе буларак әкияти чараларга мөрәҗәть итә, шул вакытта илдә булган һәм булырга мөмкин күренешләрне тасвир итә. Шулай итеп, Г.Исхакыйның «Локман хәким» әкиятендә җәмгыять моделенең гадел нигезгә корылуына, халыкның үткәне һәм бүгенгесе хөрмәт, киләчәгенә өмет белән карау турындагы хыяллары салынган булуына басым ясала. Бу әсәр үз чоры контекстында Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан иҗаты белән аваздашлык тапса, соңыннан Ә.Еники иҗатындагы Локман драматик герой белән тәңгәлләшә ала.

Әдәбият:

1. Исхакый Г. Локман Хәким әкияте. (И.Нуруллинның кереш сүзе белән) // Идел., 1990. – № 6. – Б. 4-6.
2. Гайнанова Л. Локман Хәким һәм Гаяз Исхакый // Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятлары һәм тарихлары: традицияләр һәм заман (Халыкара конференциянең хезмәтләре. 3 томда.) 2 том. – Казан: Татарстан фәннәр Академиясе, – 1992. – Б.34-36.
3. Миннегулов Х.Й., Садретдинов Ш.А. Әдәбият: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педа гогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 1994.